ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРО-МАВРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ МАВРИН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул. Центральная, д. 2а, с. Старое Маврино,
Заинский район, 423537

Үзәк урамы, 2а йорт, Иске Маврин
авылы, Зәй районы, 423537

Телефон, факс 62-0-01. Электронный адрес: Smavr.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**22.06.2023** **№ 12**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм аны гамәлгә ашыру турында» 2021 нче елның 26 нче июльдә 16 нче номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 14 апрелендәге 127-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарына, «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 26 нче июлендәге 16 нче номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Пункт 3.8 үз көчен югалткан дип таныргa

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4 . Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма**
**комитет житәкчесе** **Нургалеев Р.Г.**